| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет<br>Елантовского сельского поселения<br>Нижнекамского муниципального района<br><br>423597, Нижнекамский район,<br>с. Елантово, ул. Нагорная, 1г | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Түбән Кама муниципаль районы<br>Елантау авыл җирлеге<br>Советы<br><br>423597, Түбән Кама районы,<br>Елантау авылы Нагорная урамы, 1г |
| --- | --- |

тел. /факс (8555) 33-30-42, электронный адрес: Elant.Nk@tatar.ru,
сайт: www. elantovskoe-sp.ru


РЕШЕНИЕ — КАРАР

от 07.03.2023 г. — № 04/33-52

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмалар булдыру, аларны карап тоту һәм саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 21 апреле 5 номерлы Елантау авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Елантау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Елантау авыл җирлеге Советы карар бирә:

«Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшел утыртмалар булдыру, аларны карап тоту һәм саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 21 апреле 5 номерлы Елантау авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

10 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Яшел утыртмаларны алу гариза бирүче тарафыннан тикшерү акты нигезендә, алып ташлана торган яшел утыртмалар бәясен исәпләүнең расланган методикасы буенча исәпләнгән экологик зыян күләмендә һәм Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге территориясендә компенсацияле яшелләндерү үткәрү акчалата яисә табигый рәвештә компенсацияле (торгызу) яшелләндерү башкару юлы белән компенсацияләнә.

Акчалата компенсация гариза бирүче тарафыннан яшел утыртмаларны алып ташлауга рөхсәт бирелгәнче башкарыла.

Натураль төрдәге компенсация гариза бирүче тарафыннан яшел утыртмаларны алып ташлауга рөхсәт бирелгән көннән бер ай эчендә башкарыла. Гамәлдәге елның 15 октябреннән соң яшел утыртмаларны алып ташлауга рөхсәт биргәндә, натураль төрдәге компенсация киләсе елның 15 апреленнән бер ай эчендә гамәлгә ашырыла.».

2. Әлеге карарны мәгълүмат такталарында, шулай ук Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Прости авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

В.А. Лебедев